РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Глава
Урсаевского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Центральная, д. 60, Азнакаевский район,
с.Урсаево, 423318,
тел./факс (885592)35-0-36
E-mail: Ursaev.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Урсай авыл җирлеге
башлыгы

Үзәк ур., 60 нчы йорт, Азнакай районы,
Урсай авылы, 423318
тел./факс (885592)35-0-36
E-mail: Ursaev.Azn@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от «01» ноябрь 2023г.** **№ 5**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Мөслим торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Мөслим авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2023 елның 14 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.
2. «Сез 2024 елда Урсай авыл җирлеге Мөслим авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан,хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзәләреннән, көндезге уку формасында укучылардан тыш, 500 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан түләүне киметеп, аны 250 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:
   - Мөслим авылының тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау (Лампалар, Яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам яктыртуларын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләр);
   - су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны һәм Мөслим авылында яшәүчеләргә су бирүне тәэмин итүче су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау (килешү буенча эш өчен түләү, материаллар, җиһазлар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, торбаларны алыштыру);

- Мөслим авылындагы җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау һәм тоту ( юлларны профильләштерү , Мөслим авылындагы юлларны кардан чистарту);
- Мөслим авылында халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү (Гафури урамындагы балалар мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру);

«ЗА» «ПРОТИВ».

3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларга һәм җирлекнең рәсми сайтына кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Бу карар бастырылган көннән үз көченә керә

Башлык З.Х.Рахимьянова